КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 июль г.Казань № 601

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерү мониторингын оештыру турында» 2024 ел, 4 март, 118 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерү мониторингын гамәлгә ашыруга ярдәм итүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерү мониторингын оештыру турында» 2024 ел, 4 март, 118 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны социальләштерү мониторингын гамәлгә ашыруга ярдәм итүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «социальләштерү мониторингын гамәлгә ашыруга ярдәм итүне оештыру буенча» сүзләрен «социальләштерү эшчәнлеген оештыру буенча» сүзләренә алмаштырырга;

ведомствоара эшче төркем составыннан Р.И.Һидиятуллинны чыгарырга;

ведомствоара эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Бычкова Анжелика Хәким кызын | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгын, эшче төркем секретарен |
| Захарова Светлана Михайловнаны | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисен (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин